ӨМЕТ ҺӘМ ЯРДӘМ

«Республика гаилә диалогы» яшь гаиләләр форумында шул хакта сөйләштеләр

> 2

«ТАШКА БАСЫЛГАН»

Моны яшьләр беләме икән, өлкәнрәкләр хәтерли торгандыр әле

> 3

ИКЕНЧЕ МӘРТӘБӘ

«Ак барс» биш елдан соң янә Гагарин Кубогы өчен көрәштән беренче раундта ук төшеп калды

> 4

МОРТАЗИННАР ГАИЛӘСЕ:

«Спорт белән уку бер-берсенә комачауларга тиеш түгел. Начар билге алсалар, спортка вакыт кими»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 31 (29191) | Сишәмбе | 12 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ГАИЛӘ БӘЙРӘМЕ

САЙЛАУ КӨННӘРЕНДӘ ТАТАРСТАНДА НИНДИ ЧАРАЛАР КӨТЕЛӘ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Шимбә эшләнәсе эшләр исемлегендә сайлауга бару беренче урында тора». Сөмбел белән Самат Зыятдиновлар Россия Президентын сайлауга быел тәүге тапкыр гаилә буларак бара. Гаиләләр арасында өч машина уйнатылачагын ишеткәч, «Сайлауда катнашып, машина отсаң, әйбәт булыр иде әле!» – диеште алар.

Тавыш өчен – машина

Тумышлары белән Балтач районының Карадуган авылыннан булган Сөмбел белән Самат бу юлы Казанда тавыш бирергә җыена.

– Эш урыныбыз Казанда булгач, монда катнашырга уйладык. Яшәү урыны буенча сайлау мөмкинлеге булуын белгәч, Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза җибәргән идек, – ди Сөмбел Зыятдинова.

Яшь гаилә Россия Президенты өчен тавыш бирүдә бергә катнашырга җыена. Әлеге мөһим сәяси вакыйга үзе дә 2024 елда игълан ителгән Гаилә елы рухында узачак. Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева сүзләренә караганда, Гаилә елы уңаеннан уздырыла торган зур чараларның берсе – «Бөтен гаилә белән сайлауга» акциясе.

– Сайлау көннәрендә Татарстанда әлеге акция кысасында күпсанлы чаралар узачак. Әйтик, Татарстанда сайлауда катнашкан гаиләләр арасында өч Lada Vesta машинасы уйнатылачак. Моның өчен фотоконкурста катнашырга гына кирәк, – дип сөйләде ул сайлау көннәрендә узачак мәдәни-күңел ачу чараларына багышланган матбугат очрашуында.

Концерт та, ЭКГ да

Казан сайлауга тулысынча әзер. Казан башкарма комитеты аппараты җитәкчесе Булат Алиев шулай дип белдерде. Башкала халкын һәм кунакларны 15–17 март көннәрендә шактый гына чаралар көтә. Әйтик, Россия Президентын сайлауда катнашучылар өч көн буе җәмәгать транспортында бушлай йөри алачак.

– Тавыш бирүчеләргә «Бөтен гаилә белән сайлауга» дигән махсус беләзек биреләчәк. Шул беләзек белән 15–17 мартта җәмәгать транспортында бушлай йөрергә һәм сайлауның соңгы көнендә «Ак барс Арена»да узачак бәйрәм фестиваленә бушлай керергә мөмкин булачак, – диде ул.

Гаилә фестивале исә 17 мартта 12.00 сәгатьтә башланып, 21.30 сәгатькә кадәр дәвам итәчәк. Бәйрәмгә башкалада гына түгел, башка шәһәр яки авылда тавыш бирүчеләр дә керә алачак.

Концерттан тыш, сайлау көннәрендә башкалада 20 урында балалар өчен махсус чаралар, 170 мәйданчыкта ярминкәләр оештырылачак. «Аларда продукцияне 20–25 процентлы ташлама белән сатып алырга мөмкин булачак. Моннан тыш, 40 сайлау участогында ЭКГ узу һәм кан басымын тикшерү мөмкинлеге каралган «Сәламәтлек ноктасы» эшләячәк», – дип сөйләде Булат Алиев.

Бу көннәрдә телевизор, аерым алганда, «ТНВ» карарга җыенучыларны да махсус программа көтә. Бу хакта «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директорының мәгълүмати тапшырулар буенча урынбасары Светлана Кадыйрова сөйләде.

– Өч көн дәвамында иртәнге 8дән алып кичке 8гә кадәр «Гаилә телемарафоны» уздырырга ниятлибез. Без җәмгысы 120ләп кунак – танылган, күркәм гаиләләрне чакырдык. Моннан тыш, тәүге тапкыр «туры эфир» вакытында уен бүлмәсе эшләячәк. Әти-әниләр белән гаилә кыйммәтләре турында сөйләшкән арада, аларның сабыйлары безнең «Шаян ТВ» балалары белән булачак, – диде ул матбугат очрашуында.

Конкурста катнашу шартлары

1 15–17 март көннәрендә 08.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр сайлауга барган җирдән гаилә белән фотога төшәргә кирәк. Фотода махсус беләзек (аны тавыш биргәннән соң тапшыралар) күренергә тиеш.

2 Аннан әлеге фотоны «ВКонтакте» яки «Instagram»* битендә ике хэштег (**#всейсемьейнавыборы #ТатарстанАлга**) белән урнаштырырга кирәк.

3 Фотоконкурста республикада теркәлгән (пропискасы булган) кешеләр генә катнаша ала. Әлеге шартның үтәлгән булу-булмавы приз биргәндә оештыручылар тарафыннан тикшереләчәк.

Машиналар берәм-берәм уйнатылачак. Әйтик, 15 мартта шул көнне фото урнаштырган бер машина иясе ачыкланачак. 15 һәм 16 мартта җиңүче исеме «ВКонтакте»дагы «Татарстан Алга» төркемендә 21.00 сәгатьтә «туры эфир» вакытында билгеле булачак. Өченче машинаны 17 мартта 20.10 сәгатьтә «ТНВ» телеканалындагы «туры эфир»да уйнатачаклар. Тулырак мәгълүмат – family-tatarstan.ru сайтында.

**Россиядә экстремист дип табылган һәм тыелган оешма.*

Сайлау – 2024

Сайлау көннәре: 15, 16, 17 март

Кандидатлар: Владимир Путин (үз-үзен тәкъдим итүче), Владислав Даванков («Новые люди»), Николай Харитонов (КПРФ), Леонид Слуцкий (ЛДПР).

Юрганга карап сузасы

Халыкның кредит бурычы ягыннан Татарстан Россия төбәкләре арасында 13 нче урынга чыккан. «РИА Новости» үткәргән тикшеренү мәгълүматларына караганда, ел башына республикада кредит буенча җан башына туры килгән бурычның еллык хезмәт хакы арасындагы нисбәте 76,8 процент тәшкил иткән. Шул ук вакытта бер кешенең банкка әҗәте уртача 495 мең сумнан артып киткән. Бу сан 1 ел эчендә 118,2 мең сумга үскән.

Кредит бурычы иң күп булган төбәкләр исемлегенә Тыва, Калмыкия һәм Төмән өлкәсе кергән. 10 төбәктә исә кредит бурычы – еллык хезмәт хакының 50 процентыннан кимрәк. Беренче өч урында – Ингушетия, Кырым һәм Чечня. Гомумән алганда, 2024 елда Россиядә бер кешенең банкка уртача бурычы 439 мең сум (еллык хезмәт хакының 57 проценты чамасы) тәшкил иткән. Бер елда ул 83,7 мең сумга арткан.

Сүз уңаеннан, Татарстанның суд приставлары ел башыннан бирле бурычларын түләмәүчеләрдән 260 транспорт чарасын тартып алган.

Язгы сәүдә башлана

Казанда 16 марттан 28 апрельгә кадәр язгы ярминкәләр үткәреләчәк. Татарстан башкаласының Кулланучылар базары комитеты рәисе Руслан Фазылҗанов әйтүенчә, аларда азык-төлек чагыштырмача арзанрак бәядән сатылачак. Ярминкәләргә яшелчә, ит ризыклары, шулай ук ярдәмче хуҗалык өчен кирәк-ярак китереләчәк.

Сәүдәнең һәр атна шимбәсендә 14 урында оештырылуы күздә тотыла. «Северный» бистәсендә яшәүчеләрнең үтенечен исәпкә алып, Беломорская һәм Гудованцев урамнары чатындагы ярминкә якшәмбе көннәрендә дә уздырылачак. Барлыгы 22 район, шулай ук 19 агросәнәгать комплексы оешмасы үзләренең продукциясен тәкъдим итәчәк.

Ярминкәләр Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән кебек шәһәрләрдә, шулай ук районнарда да үткәрелә.

Иш янына куш

Татарстанда яшь физкультура укытучыларына йорт-җирләрен карауга бер тапкыр бирелә торган акча күләме 5 тапкыр артып, 100 мең сумга җиткән. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән карарга кул куйган. Документ быел 1 гыйнвардан пәйда булган хокукый мөнәсәбәтләргә, ягъни шушы көннән эшкә керүчеләргә кагыла.

Акча балаларга өстәмә белем бирүче физкультура-спорт оешмаларына эшкә кергән яшь белгечләргә биреләчәк. Түләү күләме моңа кадәр 20 мең сум тәшкил иткән.

Яңалык

Алданрак чыгасы

Россиядә кайбер кешеләр пенсиягә иртәрәк чыга алачак. Илнең Хезмәт министрлыгы пенсия яшенә җитеп килгән эшсез кешеләргә вакытыннан алда пенсия билгеләү тәртибен раслаган. Карар бүгеннән үз көченә керә.

Гамәлдәге закон нигезендә кайбер очракларда эшсез кешеләр ике елга алданрак пенсиягә чыга ала. Бу берничә очракта мөмкин. Әйтик, әгәр мәшгульлек үзәге кешене эшкә урнаштыра алмый икән, ул лаеклы ялга иртәрәк чыга ала. Вакытыннан алда лаеклы ялга чыгу өчен кирәкле иминият стажы булган (ир-атларныкы – 25 елдан, хатын-кызларныкы 20 елдан да аз булмаска тиеш. – **Ред.**) кеше дә бу мөмкинлектән файдалана ала. Кирәкле пенсия балларын туплаган кешене дә лаеклы ялга ике елга алданрак чыгарырга мөмкиннәр. Моның өчен барлыгы 28,2 балл җыелган булу шарт. Оешма бетерелү, хезмәткәрләре санын «кыскарту» аркасында эшсез калган кеше дә пенсиягә иртәрәк чыгуга өметләнә ала.

Вакытыннан алда лаеклы ялга чыга алучылар сафы моның белән генә чикләнми, билгеле. Сәламәтлек өчен зарарлы шартларда, оешмаларда эшләүчеләр, күпбалалы әниләр, Ерак Төньяк һәм аңа тиңләштерелгән районнарда эшләүчеләр дә пенсиягә иртәрәк чыга ала. Бу мөмкинлек социаль ярдәм чарасы буларак та билгеләнергә мөмкин. Ул очракта тумыштан инвалид бала тәрбияләүче ата-ананың берсе, инвалид баланы опекунлыкка алучы да лаеклы ялга иртәрәк чыга ала.

– Кешегә вакытыннан алда пенсия билгеләү өчен мәшгульлек үзәге иң элек Социаль фондтан кешенең стажы, җыелган баллары турында тулы мәгълүмат соратырга тиеш. Бу документны кеше үзе дә алып тапшыра ала. Кирәкле мәгълүматны җыйганнан соң Социаль фонд аны биш көн эчендә мәшгульлек үзәгенә җибәрә. Лаеклы ялга озатылучы, үз чиратында, вакытыннан алда пенсия билгеләүләренә ризалыгын белдереп имза куярга тиеш. Ризалык алганнан соң мәшгульлек үзәге бер көн эчендә яшәү урыны буенча Социаль фонд идарәсенә кешене вакытыннан алда лаеклы ялга чыгару турында рәсми тәкъдим җибәрергә бурычлы. Ахыргы карарны Социаль фонд кабул итә. Бу биш көн эчендә эшләнергә тиеш, – диелә министрлык хәбәрендә.

Сүз уңаеннан, 1 апрельдән Россиядә социаль пенсияләр 7,4 процентка артачак. Татарстан буенча Социаль фонд бүлеге җитәкчесе Эдуард Вафин сүзләренә караганда, бу яңалык республикада яшәүче 81 меңнән артык кешегә кагылачак.

Ел башыннан эшләмәүчеләрнең социаль пенсияләре 7,5 процентка арттырылды. Ул республикада яшәүче 900 мең кешегә кагылды. Гыйнвар индексациясеннән соң республикада пенсиянең уртача күләме 21,9 мең сум тәшкил итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

2024 гаилә елы



Рүзәл МӨХӘММӘТШИН, шагыйрь:

Гаилә – минем өчен бу дөньяның иң гүзәл, иң рәхәт, иң матур өлеше. Минем терәгем. Ышанычым. Өметем. Мине җылытып торучы учак. Дус-тату яшәр өчен, бер-береңә юл куярга, бер-береңне аңлый, тыңлый һәм ишетә белергә кирәк, мөгаен.

РОССИЯДӘ – СӘЯХӘТ ИТҮ

«Яндекс.Путешествия» халык арасында сораштыру үткәреп, россиялеләрне сәяхәт итәргә нәрсә илһамландыруын белешкән. Баксаң, бу эштә мөһим рольне социаль челтәрләр һәм танылган кешеләр уйный икән.



40% >>	блогерлар, танылган кешеләр киңәше
39% >>	сәяхәткә кисәк чыгып китә
25% >>	дусларның киңәшенә колак сала
16% >>	махсус сайтлар һәм тапшырулар карый
10% >>	социаль челтәрләрдә күргән урыннарга сәяхәт кыла

Көйсез март

Якын араларда Татарстанда һава температурасының бик нык «уйнавы» көтелә. Әйтик, төнлә термометрның терекөмеш баганасы –22 градуска төшсә, көндез +1 булачак.

Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, чәршәмбе – 13 мартта республикада көндез явым-төшем булмаячак. Төнлә кар явачак. Төньяк-көнбатыштан секундына 6–11 метр тизлектә җил. Төнлә һәм иртән –9...–14, көндез 0...+5 градус.

Исегезгә төшерәбез: 4 мартта Казанда 1995 елгы температура рекорды (+3,9 градус) челпәрәмә килеп, +4 градус тәшкил итте. Быел февраль аенда метеорологлар, дөнья күләмендә уртача һава температурасының, күзәтүләр тарихында беренче тапкыр, иң җылы булганлыгын әйтте.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ХАКИМЛЕККӘ БАНДИТЛАР КИЛГӘНДӘ

Дөньякүләм турбулентлык һаман үзенең югары ноктасына омтыла. Өченче дөнья илләрендә дә, икътисадый яктан алга киткән илләрдә дә протестлар масштаблы һәм кискенрәк була бара. Европада фермерлар протесты туктамый һәм радикальләшә. Без гел ассызыклыйбыз: авыл хуҗалыгы өчен җир, Без гел ассызыклыйбыз: авыл хуҗалыгы өчен дилемма яшәү-үлем сызыгы буларак сызылган. Үткән атнада поляк фермерлары Премьер Дональд Туск белән очрашты. Аларның таләпләре гади: илгә читтән азык-төлек кертүне (бигрәк тә Украина ашлыгын) туктатырга, «яшел көн тәртибе»ннән баш тартырга. Көнбатыш лидерлары бит үзләрен акылдан язганча тоталар: сыерлар экологиягә начар тәэсир итә дип, терлекчелекнең тамырына балта чапмакчылар. Фермерлар нигездә менә шул тиле сәясәткә каршы. Туск фермерлар белән очрашуда үзенең аяк-куллары бәйле булуын һәм берни дә эшли алмавын әйткән. Фермерлар көрәш кайнарлыгын югарырак температурага күтәрергә булды. 20 мартта барлык юлларны һәм шәһәрләрне блокадаларга ниятлиләр. Үткән атнада Варшавада хәл болай да кискенләште: полициягә брусчатка ыргытучылар пәйда булды. Соңыннан яңа технологияләр (йөзне тану программалары) ярдәмендә аларның киемен алыштырган полицейскийлар булуы ачыкланды. Димәк, провокацияләр ярдәмендә протест хәрәкәтен тыймакчы булып азапланалар. Бер Польша гына түгел, Европаның барлык илләрендә дә сыерларны яклап протест туктамый. Чехия шәһәрләре тирескә батты. Француз һәм испаны фермерлар чикләрне ябуда үзара берләшә.

Яңалыклар лентасы планетаның башка төбәкләреннән дә кайнар хәбәрләр китерә. Мексикада протест белдерүчеләр Президент сараеның капкасын ватты. Иң киеренке вазгыять – Гаитида. Анда инде берничә көн дәвамында хөкүмәт көчләре белән коралы бандалар арасында бәрелеш бара. Премьер-министр Ариэль Анри ярдәм сорап чит илгә киткән җиреннән илгә кайта алмый, чөнки аэропорт фетнәчеләр кулында. Коралы бандитлар башлыгы Гай Филипия, Премьерны хакимлектән читләштереп, үзен Президент итеп игълан итәргә җыена. Ул 2004 елда бер тапкыр уңышсыз дәүләт түнтәрелеше ясап караган инде. Быелгысы уңышлырак: төрмәләр ачылды, җинаятьчеләр ирекkә чыгарылды. Без вакыйгаларның асылын белә алмыйбыз, аларның рәсми яктыртылышын гына сөйлибез. Рәсми пропаганда фетнәчеләрне туры мәгънәсендә бандитлар дип атый. Американнар ил башкаласы Порт-о-Пренстагы илчелек хезмәткәрләрен 10 мартка каршы төндә диңгез пехотачылары ярдәме белән эвакуацияләделәр.

Сәясәтнең тектоник плитәләре барлык континентларда да кискен хәрәкәттә. Аларны тасвирлау өчен мәйдан җитәрлек түгел.

Россиядә

БӘЯЛӘР КҮТӘРЕЛӘ, ФӘКЫЙРЬЛӘР КИМИ

Дөньякүләм кризис Россия икътисадында да чагыла, билгеле. Әмма бездә тынычлык хөкем сөрә. Халык сабыр: бәяләр күтәрелү һәм тормыштагы кыенлыклар кухня сөйләшүләреннән узмый. Сабырлык «тимер законнар» белән ныгытыла. Хәзерге кануннар зарланучыларны яратмый. Аннан соң Росстат гел күңелле хәбәрләр генә ирештерә. 2023 ел нәтиҗәләре буенча илдә фәкыйрьләр саны кимегән: 13,5 миллионнан да азрак калган. Бу – ил халкының 9,3 проценты. 1992 елдан соң беренче тапкыр шундый уңай нәтиҗәгә ирешелгән. Рәсми белгечләр моны балалы гаиләләргә адресны пособиеләр бирелү, эш урыннарының артуы (ягъни эшсезлек кимү), хезмәткә түләүнең минималь күләме һәм хезмәт хакларының артуы белән аңлата. Дөрестән дә, ябык хезмәт хакы алырга теләүчеләр өчен эш урыннары артты. Хәтта квалификация таләп ителмәгән югары хезмәт хаклы эш урыннары пәйда булды. Вазгыять тагын да шулай дәвам итәрме, ягъни бәяләр күтәрелгән саен фәкыйрьлек артка чигенерме – әйтү кыен. Ил икътисадына кыенлесз фактлар саны да ишәя. 2021 елдан соң беренче тапкыр бизнесның банкротлыкка чыгуы арткан. Гыйнварда 571 компания бөлгенлек игълан иткән, февральдә – 771. Гыйнварда 2023 елның шул чоры белән чагыштырганда үсеш – 57 процент, февральдә – 61. Бик зур темплар бу. Дөрес, белгечләр, саннар аномаль түгел, ди. Әмма макроикътисадта башка күңелсез фактлар да үсә. Аннан соң бик яхшы үсештә дип табылган тармакларда да тирәнгә ишерелгән проблемалар баш калкыта. «Сельское хозяйство для России становится источником нестабильности» дигән баш астында язма бирә бер федераль газета. Ә бит авыл хуҗалыгы елдан-ел яхшырак күрсәткечләргә ирешә. Әммә монда да парадокс: җитештерү арта, рентабельлек кими. Соңгысының кимүе хөкүмәтнең авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләрне бәйләп тотарга тырышуы сәбәпле. Безнең фермерларның хөкүмәткә дәгъва белдерерлек урыннары юк, әлбәттә. Җитештерү субсидияләнә, шуның аша бик югары булмаса да, түзәрлек тормыш дәрәҗәсе тәэмин ителә. Ләкин рентабельлекнең минуска китүе чәчүлек җирләренең кимүенә китерер дип көтәләр. Бездә беркем дә әлегә сыерларны пычак астына җибәрүне таләп итми, әмма баш саны кими. Йомырка кризисына охшаган янә бер кризис мәйданга чыкмас дип әйтеп булмый.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ: «ҮЗ ЭШЕМНЕ ҺӘРВАКЫТ ЯХШЫ БАШКАРЫРГА ТЫРЫШТЫМ»

Иң яхшысы булырга тырышыгыз. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов СИБУР хезмәткәрләре белән очрашуда әнә шундый киңәш бирде. Ул оешманың бизнеска эксперт ярдәме үзәге ачылышында катнашты.

Билгеле булганча, «Казаноргсинтез» сәнәгать мәйданчыгы янәшәсендә СИБУРның эшлекле кварталын булдырырга җыеналар. Рәискә тәкъдим ителгән үзәк – шул кварталның беренче объекты.

СИБУР компаниясенең бизнеска эксперт ярдәме үзәге Татарстанда заманча эш мохите булдыру буенча зур программаның бер өлеше булып тора. Ул җитештерү, фән һәм административ бүлекчәләрнең нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итәчәк.

Бер ел дигәндә, әлеге бина тулысынча реконструкцияләнгән. Уртак эш өчен күпфункцияле зоналар ачылган. Сүз уңаеннан, бу проектны тормышка ашыру хакы – 1,3 млрд сум.

tatarstan.ru

Хезмәткәрләр белән аралашу барышында Рөстәм Миңнеханов үзенең уй-кичерешләрен дә җиткерде.

– Монда берничә тапкыр булганым бар. Бүген бик күп яңалыклар күрдем. Компания тырышкан. Монда эш ничек көйләнгәнен тыңлау кызыклы булды. Искиткеч хезмәткәрләр эшләвен күрдем, – диде ул.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов үзенең һөнәри яктан ничек үсүе турында да сөйләде. Сүз уңаеннан, СИБУР ике ел дәвамында «Галстуксыз очрашулар» оештыра икән инде.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, СИБУР җитәкчелеге коллектив эшен оештыру, уңайлы хезмәт шартлары булдыру өчен шактый көч куйган.

– Үзгәрешләр гел ниндидер өметләр уята. СИБУРдагылар бик күп яңалыклар алып килде. Беренчедән, бу эшчеләргә мөнәсәбәт. Эшчеләрнең тукланиуын оештыру мәсьәләсе хәл ителде. Җитди максатлар бар, – диде Рәис. – Күрегез: Мәскәү, Түбән Новгородтан безгә – Казанга күченеп киләләр. Казанның шундый җәлеп итү үзәге булуы куандыра. Без бу юнәлештә гел эшлибез.

Кадрлар мәсьәләсенә дә игътибар итте Татарстан Рәисе.

– Яңа белгечләрне табып, аларга мөмкинлекләр бирергә кирәк. Барысы да үзебездән тора. Мәсәлән, мин әллә ни зур үрләргә омтылмадым, әмма эшемне гел әйбәт башкарырга тырыштым. Татарстан белән инде 14 ел идарә итәм. Әммә болай ук булыр дип һич уйламаган идем. Бигрәк тә инженер булып эшләгәндә. Районадагы башкарма комитет рәисенә кадәр үсәрмен дә шул булыр дип уйлый идем. Сезгә эшне ышанып тапшырсыннар өчен тырышырга һәм иң яхшысы булырга кирәк.



Хәерле сәгатьтә!

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казан вертолет заводында җитештерелгән биш яңа Ми-8МТВ-1 вертолетын авиакомпанияләргә тапшыру тантанасында катнашты.

– Бүген бездә бик мөһим вакыйга. Биш Ми-8МТВ-1 вертолетын тапшырабыз. Бу – авиация тарихындагы иң универсаль машиналарның берсе, ул үзен күп төрле бурычлар үтәүдә ышанычлы булуын күрсәтте, – диде Рәис тантанада. – Без ил җитәкчелегенә ярдәм итү программалары өчен рәхмәтле. 2026 елга кадәр Дәүләт транспорт лизинг компаниясе һәм Казан вертолет заводы илнең төрле төбәкләренә 70 яңа вертолет тапшырачак. Бу – зур сан.

Бу күп максатлы вертолет теләсә нинди климат шартларында кулланыла ала. Анда яктылык-техник җиһазландыру яңартылган. Һава машиналарында пассажирлар өчен 23 урын каралган. Медицина модульләрен урнаштыру өчен дә урын җитәрлек. Зур (4 тонналарга кадәр) йөкләр ташу да мөмкин.

Шулай итеп Ми-8МТВ-1 очкычын «Комиавиатранс», «Лидер», «Витязь-аэро», «Дальнереченск Авиа» компанияләре алды.

Яшәеш

КУЛГА КУЛ ТОТЫНЫШЫП

КАЗАНДА ЯШЬ ГАИЛӘЛӘР ФОРУМЫ УЗДЫ

2024 гаилә елы

Өмет һәм ярдәм. Казанда узган «Республика гаилә диалогы» яшь гаиләләр форумында шул хакта сөйләштеләр. Стратегик сессиядә 25 районнан 80гә якын яшь гаилә катнашты. Форумда яңгыраган төп фикерләр – безнең язмада.

Татарстан – үрнәк!

Катнашучыларны Россия Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова сәламләде:

– Бүген монда Татарстанның яшь, иҗади, креатив һәм матур гаиләләре җыелган. Быел – яшь гаиләләр, тормыш стажы зур булган тәҗрибәле гаиләләр һәм ныклы терәк – өлкән яшьтәге гаиләләр елы. Ул безнең бетен халыкка кагыла, – диде Татьяна Ларионова. – Әлбәттә, гаилә яшьләрдән башлана. Бүген монда ныклы һәм, күзләрегездән күрәм, бәхетле гаиләләр булуына бик шатмын. Шундый булганлыгы өчен рәхмәт! Без һәр елны Гаилә елы булсын өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә тиеш. Ләкин бу бик катлаулы. Ничек кенә булмасын, Татарстан – ныклы гаиләләр төбәге.

Гражданлык никахы – гаиләме?

Мөһер кирәкме? Татьяна Ларионова никахсыз гаиләләр проблемасына аерым тукталды.

– Телибезме, теләмибезме, бүген бик күп яшьләр никахсыз яши. Бәлки, алар үз тормыш рәвешләрен гаилә дип санныйлардыр. Ләкин, кызганыч, бу вакытлыча гына. Еш кына андыйлар, шул исәптән яшь әти-әниләр, балалары турында уйламыйча, кайсы кая таралыша, – дип сөйләде депутат. – Гаилә ельнда без күп сорауларга җавап табарга тиеш. Ни өчен никахсыз яшәү нормага әверелде? Ни өчен аерылышулар күбәя? Статистика буенча, Россиядә 10 никахның 7се таркала. Бүген әтисе яки әнисе белән генә яшәүче балалар, үз сабыйларын ташлап кына кУченеп, алиментны вакытында түләмәгән әтиләр күп. Бу мәсьәләнең барысын да хәл итәргә кирәк.

Ярдәм

Һәрбер гаилә өмет белән яшәсен өчен нәрсә эшләргә кирәк?

– Аңлашыла ки, һәр яшь гаилә үз йорты, фатиры турында хыялланa. Программа эшли, ләкин, кызганыч, ул җитәрлек түгел. Бүген бу хакта министр белән дә сөйләштек, – ди Татьяна Ларионова. – Дәүләт матди ярдәм күрсәтә, бүген мондчы күрелмәгән социаль ярдәм чаралары бихисап. Өч ел элек алардан 960 мең гаилә файдаланган. Бүген, икенче ел бирелә торган бердәм пособиене исәпкә алып, 11 миллионга якын гаилә социаль ярдәм чаралары ала. Әлбәттә, гаиләле яшьләргә эш кирәк. Чыннан да кызыклы эш һәм лаеклы хезмәт хакы булса, аларга дәүләт пособиеләренең кирәге дә булмый. Югары белем алган яшьләрне һөнәр буенча ничек эшләтергә һәм ул һөнәрне ничек кызыклы, абруйлы һәм керемле итәргә? Барлык бу сорауларга җавап табар өчен бөтен Россиядән яшь гаиләләрне җыеп, шундый ук стратегик сессия үткәрергә телибез. Бүген сезнең әстә җаваплылык бик зур. Сез үзегезнең генә түгел, бөтен Татарстан гаиләләре турында уйларга тиеш. Мин сезгә өметләнәм.

Дөрес юнәлештә барабызмы?

Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков яшь гаиләләрдән әнә шулай дип кызыксынды.

– Форумда 25 районнан 80гә якын яшь гаилә катнаша. Бу – укытучылар, эшмәкәрләр гаиләләре, күпбалалы гаиләләр, хезмәт династияләре, махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләре. Соңгы 10 ел белән чагыштырсак, дәүләт тарафыннан яшь гаиләләргә ярдәм итүдә зур үзгәрешләр булды. Бүген безгә ныклы гаиләләр төбәге статусын саклап калу өчен нәрсә эшләргә кирәклеген аңлау мөһим, 2, 5, 10 елдан соң да республиканың 4 миллионнан артык халкы булуы һәм социаль-икътисадый күрсәткечләрне арттыру кирәк, – диде министр. – Без сезнең белән сөйләшергә әзер. Хакимият халыкны тыңламый, диләр. Республикада мондый хәл беркайчан да булмады һәм булмаячак та. «Республика гаилә диалогы» – яшь гаиләләр белән әңгәмә өчен зур һәм әһәмиятле мәйданчык. Сезне актив булырга чакырам.

Ләйсән САФИНА

КИЛӘЧӘККӘ ЮЛ

«ВОЛГА» ЭКСПЕРТЛАР КЛУБЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫНДА САЙЛАУДА КАТНАШУНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

ТАТАРСТАН — КАЗАНЫШ ҖИРЕ

Бу атнада илдә мөһим сәяси чара – Россия Президентын сайлау узачак. Аннан соң тормыш бармы? Безне нинди киләчәк көтә? Гомумән дә, сайлауда катнашу мөһимме? Әлеге һәм башка сорауларга «Волга» экспертлар клубының чираттагы утырышында җавап эзләделәр.

Билгеле ки, илнең иртәгәге көнен күзаллауда Россия Президенты Владимир Путинның ике атна элек Федераль Җыенга Юлламасы әһәмиятле урын алып тора. Бу – безнең киләчәк юлыбыз. Аны кем һәм ничек тормышка ашырасын исә Россия Президентын сайлау барышында бергәләп хәл итәчәкбез. Шуңа күрә дә сайлауда катнашу мөһим. Федераль Җыенга Юллама исә тормышның төрле юнәлешләре буенча киләчәкне күзалларга ярдәм итә, диделәр утырышта.

Тотрыклылык турында

– Сайлау көне якынлашкан саен һәркем: «Кем өчен тавыш бирергә?» – дигән сорауга җавап табарга тырыша, – ди Федераль Җыенның Федерация Советы әгъзасы, Регламент һәм парламент эшчәнлеген оештыру буенча комитет җитәкчесе урынбасары Александр Терентьев. – Россия Президентының Федераль Җыенга Юлламасы алдагы алты елга илнең сәяси курсын билгеләде. Стратегик тәкъдимнәр сәнәгать үсешен тәэмин итүне дә, социаль программалар үтәлешен дә күз уңында тота. Бу – тотрыклылык һәм гаделлек билгесе.

Бүгенге шартларда илебезнең берләшүен дә исәпкә алмыйча мөмкин түгел. Александр Терентьев әйтүенчә, Россия кебек күпмилләтле ил өчен әлеге сыйфат аеруча да мөһим:

> Дәүләтебезнең моңарчы бу кадәр берләшкәне юк иде әле. Илебез алдында торган бурычлар бездән бер йодрык булуын таләп итә. Сайлау кампаниясе кысасында да, сәяси көрәш мәйданына кемнәр һәм ничек чыгуын үзебез күреп торабыз. Быелгы сайлау кампаниясенең үзенчәлеге – Россия Президенты вазыйфасына кандидатлар Илбашы куйган бурычлар, ул алып барган сәяси курс тирәсендә берләште.

Александр Терентьев сүзләренә караганда, алда торучы сәяси чарада «көчле Россия» гыйбарәсе кызыл җеп булып уза.

– Юлламада күпбалалы гаиләләргә ярдәм, кадрлар резервы, махсус хәрби операция турында да күп әйтелде. Болар барысы да халыкка бик якын. Бу – яңа курс түгел. Илбашы анын кайсы урыннарын камилләштерергә кирәк икәнен яхшы аңлый. Ил алдында торган бурычлар билгеле. Алар төрле катлауга кагыла. Шул ук БДИ да – халыкны борчыган мәсьәлә. Бу хакта еш ишетәбез бит. Юлламада күтәрелгән мәсьәләләрнең барысы да тормыштан алынган, – диде Александр Терентьев.

Тотрыклы киләчәкне әнә шулай күзаллады ул.

Гаделлек турында

Иртәгәге көн турында сөйләшкәндә, КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты директоры урынбасары, социология фәннәре докторы Мария Ефлова тагын бер нәрсәгә игътибар итте: моңарчы халык арасында үткәрелгән төрле социологик сораштырулар барышында респондентлар керемнәр кимүгә, бәяләр артуга борчылу белдергән булган. Юлламада әлеге сорауга да җавап бар. 2030 елга кадәр илдә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме ике тапкыр диярлек артып, 35 мең сумга җитәргә тиеш.

– Бюджет тармагы хезмәткәрләренә айлык акча түләү системасына үзгәрешләр керәчәк. Яңалык гомуми, урта, югары белем бирү тармакларына да кагыла. Шулай ук, мәктәпләрдә һәм көллиятләрдә директорларның тәрбия эшләре буенча киңәшчеләренә хезмәт хакы түләүдә дә яңалык бар. Бу да бик мөһим. Гомумән алганда, үзгәрешләр ярдәм чаралары таләп ителгән катламнарны колачлый, – диде белгеч.

Уңайлы мохит турында

Киләчәк бүгеннән башлана, билгеле. Иртәгәге көнне матур итеп күзаллау өчен хәзер тиешле шартлар кирәк, ди «Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фонды директоры Наилә Зиннәтуллина.

– Россия Президенты тәкъдим иткән Юлламада төп ике яңалыкны искә алыр идем. Беренчедән, «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырылучы «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» программасы 2030 елга кадәр озайтылачак. Ул Татарстанда инде дистә елга якын гамәлдә. Әлеге программа өчен генә дә алдагы алты елда тагын 360 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Шулай ук, кече шәһәрләргә ярдәм итүне дә дәвам иттерәчәкләр. «Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр» бөтенроссия конкурсы 2030 елга кадәр гамәлдә булачак. Әйтергә кирәк, Татарстан әлеге конкурста катнашучылар ягыннан да, сыйфат мәсьәләсендә дә әйдәп баручыларның берсе. Минем уйлавымча, әлеге төр ярдәм республика халкына, шәһәр халкымы ул, әллә авылда торучылармы – барыбер, уңайлы шартлар тудыруда һәм кайгыртучанлык күрсәтүдә ярдәм итәчәк, – диде җитәкче.

Хәер, республикада уңайлы мохиткә караш та үзгәргән инде. «Бу эшкә яңа тотынган вакытта кеше күбрәк йөргән урамнарны, паркларны тәртипкә китерергә тырышсак, ун елга якын вакыт эчендә без зур юл уздык, – диде ул. – Бүген тагын да зуррак бурычлар куябыз. Халык арасында да төзекләндерелгән иҗтимагый киңлекләр өчен җаваплылык хисе бар.

Икътисад турында

Илнең икътисадый үсешен күзалларга керешкәнче, бүген нинди шартларда яшәвебезне аңларга кирәк, ди Александр Терентьев:

> Барлык тышкы чакыруларга карамастан, Россиянең халыкара мәйданда ныклы тоткан урыны бар. Безнең артка чигенергә юл юк. Бәхетсезлек булышмаса, бәхет булмас иде, дигәндәй, без бик күп нәрсәне яңабаштан аңладык. Әйе, бер мәлдә авиация, станоклар төзелеше кебек тармакларсыз калдык кебек. Бүген исә бу һәм башка юнәлешләрдә киңкүләмле программалар тормышка ашырыла. Могҗиза көтәргә кирәкми. Без үз киләчәгебезне үзебез хәл итәргә тиеш.

Эльвира ВӘЛИЕВА

САЙЛАУДА КАТНАШУ НИ ӨЧЕН МӨҺИМ?

Марсель ГЫЙЛЬМИЕВ,
«Диалог Регионы» оешмасының Татарстандагы бүлеге җитәкчесе:
– Иң беренче чиратта, бу – безнең гражданлык бурычы. Икенчедән, үзеңнең, гаиләңнең, илеңнең киләчәген күзалларга тырышудан гыйбарәт. Сайлау участогына килүче һәркем моны тәгаен ачык аңларга тиеш. Өченчедән, йөрәгең кушканча тавыш бирергә кирәк дип саныйм. Бу – үзебезгә, гаиләбезгә, илебезгә карата мөнәсәбәт белдерү дә.

Мария ЕФЛОВА,
КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты директоры урынбасары, социология фәннәре докторы:
– Мин күбрәк студентлар белән эшләгәч, аларны истә тотып әйтәсем килә. 18 яшь тулгач, кеше мөстәкыйль тормышка аяк баса. Шуңа күрә балигъ булу яшенә җиткән һәркем сайлау участокларына килсен иде, дип телим. Чөнки бу – җаваплылык. Син яңа мөмкинлекләр, яңа мохит, яңа шәһәрләр өчен тавыш бирәсең бит. Илдәге үзгәрешләргә катнашың булуын сизү бик мөһим.

Наилә ЗИННӘТУЛЛИНА,
«Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фонды директоры:
– Без көн саенниндидер сайлау алдында торабыз. Иртән нәрсә ашарга, кич ничәдә йокларга ятарга, эштә нинди карар кабул итәргә икәнен хәл итәбез. Көндәлек тегe яки бу сайлау безнең бүгенге, иртәгәге көнне хәл итәргә мөмкин. Ә Россия Президентын сайлауда катнашу – алдагы алты ел өчен хәлиткеч чара булып тора. Татарстанда яшәүчеләрнең иҗтимагый тормышта актив катнашуын исәпкә алып, бездә: «Сайлауга барыргамы, юкмы?» – дигән сорау булмаячак та дип саныйм. Барырга, әлбәттә.

Владимир КУТИЛОВ,
«Теория Дарвина» агентлыгы генераль директоры, сәяси киңәшче:
– Әгәр без киләчәкне күзаллау турында сөйлибез икән, берсүзсез тавыш бирүдә катнашырга кирәк. Бу – безнең хокукыбыз. Без үз киләчәгебезне үзебез хәл итә алабыз. Бу – безнең илкүләм, суверен хокукыбыз.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Рецепт

Ташка басылган сүз дигән төшенчә бар. Моны яшьләр беләме икән, өлкәнрәкләр хәтерли торгандыр әле. Чынында ташның бер катышы да юк инде монда, басма хәреф белән типография кебегрәк җирдә чыгарылган язмалар турында сүз бара. Язу машинкасында булса да икеле-микеле уйларга урын калдыра әле ул, ә менә типографиядә чыкканы... Китапларда яки газета-журналларда дөнья күргәне... Болары инде, чынлап та, гади генә була алмый. Менә шул ташка басылган сүз дөреслекнең үзе булып тоела торган иде. Шулай булмыйча, әллә күпме акыллы кеше тикшергән бит инде аны, хәреф хатасына кадәр төзәткән. Монда бернинди ялгышлык була алмый, димәк – дөреслек.

Компьютерлар бу күренешне беркадәр гадиләштерде. Хәзер кулдан язучы сирәк, бөтен текст та диярлек компьютерда җыела. Принтерга яки экранга чыкканда ул инде чын мәгънәсендә «ташка басылган» дөреслек кебек күренә. Дөреслеккә беркадәр якынрак торса, бигрәк тә. Ә интернет һәр кешегә үз сүзен ташка басу мөмкинлеге бирде. Социаль челтәрләрдә, төрле сәхифәләрдә гел «ташка басылган» сүз. Шуңа күрә аларга беренче караштан ук ышанасың. Янында бик матур фоторәсем дә булса, бигрәк тә. Хәзерге заманда беренче караштан ышандыра алу сәнгате – бик зур нәрсә, чөнки бөтен кеше дә каядыр ашыга һәм икенче тапкыр карап тормаска да мөмкин. Ашыкмаса да карамый. Иренә. «Җиде кат үлчә, бер кат кис» дигән мәкаль эшләми хәзер. Кеше күп очракта бер тапкыр да үлчәп тормый, тота да кисә. Һәртөрле мәгълүматны бер тапкыр да уйлап тормыйча гына кабул итә торган кешеләр дәверенә килеп җиттек. Күзгә бәрелеп торган нәрсәләрне күрә алган кеше безгә тылсымчы сыманрак тоела.

Бер танышым эшеннән китәргә мәҗбүр булган да интернетта үзенә шөгыль тапкан. Яхшы түлиләр, бик көч чыгарып, нервы бетереп эшлисе юк икән. Сөенеп туя алмый инде. Эш дигәне бик тә гади генә. Һәртөрле ризык пешерү рецептлары язып бирә икән.

Моны ишеткәч, мин башта кычкырып көлеп җибәрдем. Шаяртадыр дип уйладым. Чөнки белеп торам бит инде: бу егет йомырка да кыздырып ашый белми. Шуңа күрә, берәр җиргә китәргә кирәк чагында, хатыны ашарына пешереп, аны пакетларга салып, суыткычта калдыра. Кайсы көнне кайсы пакетны алып кереп җылытырга икәнен язып та китә әле. Бу барыбер бутый, я пешмәгән фарш алып кереп җылыта, я песигә дигән консервыны ача. Гадәти ир кеше инде, кыскасы.

Менә шул егет аш-су рецептлары язып акча эшли икән. Гаҗәпләнеп бетергәч, башыма килгән беренче уй шул булды: берәр җирдән күчереп яза торгандыр. Юк, алай да түгел икән. Монда төп таләп – текстларның уникальлеге, плагиат эзләү программалары белән тикшереп тә карыйлар икән. Аннан соң мин «рерайт» дип атала торган нәрсәне искә төшердем. Монысы татарда еш кулланылмый, шуңа ни икәнен аңлатып китәргә кирәктер. Билгеле бер текстны үз сүзләрең белән күчереп язу «рерайт» дип атала. Җөмләләрнең рәвешен алыштырасың, синонимнар кулланасың. Әмма бу шөгыль бик үк җиңел нәрсә түгел, яхшы сыйфатлы итеп эшләү яңа текст язудан да кыенрак. Танышым да кул гына селтәде: «Кит әле, шулкадәр мәшәкатькә батып ятарга сантыймы әллә мин...» Ахыр чиктә, серен чишәргә булды.

Барысы да гади генә икән. Билгеле бер рецептны бу ала да тегендә кулланылган нәрсәләрнең исемен алыштыра. Әйтик, кишер салырга кирәк икән, бу чөгендер дип күрсәтә. Исемен алыштырып булмаган очракта, дозасын үзгәртә – 120 грамм түгел, ә 125 грамм. Антиплагиат аша карасалар да бер генә рецепт та тулысынча уникаль була алмый, чөнки анда даими кулланыла торган сүзләр була. Төрле җирдән кирәкле фотолар җыя бу. Шул аш-су рәсемнәрен фотошопта бераз үзгәртә, яктылыгын, төсләрен алыштыра. Менә шул рәвешле маташтыра торгач, менә дигән аш-су рецепты килеп чыга икән. Һәм аны фәлән сумга сатып алалар. Аш-су рецептлар тәкъдим итүче сайт өчен бит инде бу. Монда беркем дә ул рецептны тикшереп, шуның буенча ризык пешереп утырмый. Иң мөһиме, сайт даими рәвештә тулыланып барсын, керүчеләр саны артсын, нәтиҗәдә реклама акчасы килеп торсын. Сайт оештыручыларга яхшы рецепттан бигрәк, уникаль язма кирәк. Ә уникаль контент әзерләүчегә җиңел акча кирәк. Калганы мөһим түгел. Шул рецепт буенча ашарга пешергән хуҗабикә турында уйлап та караучы юк. Фәлән сумга сатып алган күпме ризыгы юкка чыга аның, күпме вакыты әрәм була – беркемне кызыксындырмый.

Менә шундый сайтлардан аннан берне, моннан берне җыеп, аш-су рецептлары китабы чыгаручылар да бар бит әле. Монысы инде – интернет кына түгел, ә чын мәгънәсендә ташка басылган рецептлар. Дөреслекнең үзе шикелле. Фәлән сумга шундый китапны сатып алып, фәлән сумлык ризыгын чүпкә чыгарган хуҗабикәләр дә бардыр инде. Кызганыч, әлбәттә. Файда китерерлек урында үзенә шөгыль таба алмыйча, шундый шикле кәсепкә кереп киткән танышым да кызганыч. «Файда» белән «керем» төшенчәләрен бер үк яңгырашлы иткән заман үзе дә кызганыч. Кешеләр ышанычын югалту зур югалту бит инде. Шуңа көйләнгән тормышның кая илтеп бәрәчәген дә чамалау авыр.

Тик нишлисең... Авыр дип, кызганыч дип елап утырып булмый. Теге рецептларның берәрсе буенча ашарга пешереп карыйм әле, бәлки, кәеф күтәрелеп китәр...

КОТЛЫЙБЫЗ!

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре **Гыйльманов** Рафаил Вәли улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Чулпан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Әлмәт районы) **Мостафин** Марат Сарыйм улы, «Союз-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты (Әлмәт шәһәре) **Сидоров** Анатолий Михайлович, «Хәмәдишин Ирек Шакирҗан улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Хәмәдишин** Ирек Шакирҗан улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппараты супервайзинг идарәсенең скважиналарны капиталь төзекләндерү, скважиналарны җир астында төзекләндерү, ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм скважиналарны эшләтү буенча супервайзинг бүлеге башлыгы **Әбләмитов** Руслан Фикрәт улы, «Татнефть-Автомобильләргә ягулык салу станцияләре үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Чичков** Вячеслав Михайлович **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

«Менделеевскагрохимсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Әхмәтов** Назимулла Нурулла улына, «Муллагалиев Адел Рафаил улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы идарәчесе (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Крутиков** Василий Александровичка, «Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механигы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Хәлилов** Ринат Габдрахман улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Авыл капкасы

Илдар Мөхәммәтҗанов

Уңыш сере – бердәмлектә

Әлмәт районының Бишмунча авылында яшәүче Салават Гафиятуллин атчылык, сарыкчылык белән шөгыльләнә, үгезләр үрчетә. Авылны бар булмышы белән яратса да, төп эше шушында булса да, гаиләсе шәһәрдә яши. Сәбәп нидә? Бу хакта без аның үзеннән сорадык.

Салават – Бишмунча егете. Көллият, аннан соң институт тәмамлап, нефть тармагында эшләп йөргән егетне авылга чакырып кайтаралар.

– Иң элек эшнең атларга бәйле булуы җәлеп итте, – дип искә ала ул. – Яшь вакытта әти-әниләр хуҗалыгында һәрвакыт атлар тота идек. Шуңа күрә алар миңа бик якын. Ул чагында 15 яшь кенә тай иде алар, бүген инде атларның баш саны 80гә кадәр җитте. Дөрес, саннар гел уйнаклап тора, ләкин илледән киметкәнем юк.

Салават атларны эшкәртеп, ит ыслап, колбаса ясап сата. Моннан тыш, 500 гектар җирендә ашлык, күпьеллык үлән үстерә.

– Атлар белән бераз эшләгәч, сарыклар да үрчетергә кызыгып киттем. Аларын корбанлыкка бик күп алалар. Барысын да үзебезнең территориядә чалып, эшкәртеп, әзерләп бирәбез. Авылыбызның хәзрәтен дә шушында ук чакырабыз. Ел саен Корбан гаетенә 100–150 кеше корбанлык алып китә, – ди ул.

Җире булгач, саламы да кайта, икмәге дә бар. Шуңа күрә ат һәм сарыклар янына үгезләр дә алып җибәрергә була. Шулай итеп, хуҗалыкка 15 баш үгез дә кайтартыла.

– Урып-җыюны тәмамлагач, үгезләр алып кайтып куям да, шуларны үстереп, кышын суеп сатабыз. Үгезләрнең баш саны азрак, ләкин карар, тәрбияләр өчен иң мәшәкатьлесе дә шулар. Ат белән сарык тәрбияләр өчен көйсез түгел. Тамаклары тук булса, шул җитә. Шәхсән үземә аттан да җайлырак мал юк кебек тоела. Кышын печән, ашлык ашатсаң, җәй буе болында йөри алар.

Яшь фермер эшен 3–4 хезмәткәр белән генә башлап җибәрә. Тора-бара эшчеләр санын 20гә җиткергән. Иң мөһиме – барысы да шушы авыл егетләре. Димәк, үз авыл халкын эш белән тәэмин итә дигән сүз.

– Терлекчелектә эшем күп булса да, нефть тармагындагысын да ташлап бетермим, чөнки, кызганыч, җир эше белән алга китеп булмый. Мин терлекчелектә дә, игенчелектә дә эшләргә риза. Рентабельлек булса, бөтенләй авыл хуҗалыгы белән генә шөгыльләнер идем. Ләкин җир белән эшләү финанс мәсьәләсендә бик авыр. Никадәрле көч кертеп тапкан икмәкнең бәясе булмау күңелне төшерә.

Игенчелек янында терлекчелеге дә булырга тиеш аның. Мин бит үзем генә түгел. Эшчеләремә дә кышын эш кирәк. Алар кышын таралышып бетсә, җәен каян җыеп аласың? Шулай булгач, барысына да өлгерергә туры килә, ләкин иң мөһиме – таянырдай иптәшләрем булу. Егетләр белән бергәләп алып барганга, авырлык сизелми.

Эшчеләр дә елдан-ел арта бара, чөнки эш шартлары тудырылган, хезмәт хакларын вакытында түлибез. 35 мең сумга эшләүчесе дә, 50–60 мең сум алучысы да бар, – ди Салават Гафиятуллин.

Ләкин нинди генә уңышлы эш булса да, авырлыкларсыз булмавын барыбыз да белә. Әйтик, фермер көтүлек җирләре бик аз булуын да әйтеп узды. Төп эше, тапкан малы, әти-әнисе, туганнары авылда булса да, Салаватның хатыны белән ике баласы үзләреннән 15–20 чакрым ераклыктагы Әлмәт шәһәрендә яши.

– Авылны бик яратам. Балалар да монда кайтырга ярата. Тик, кызганыч, Бишмунчада башлангыч мәктәп кенә бар. Без сыйныфта 23 бала укыдык. Әле шуларның да биш-алтысы гына бүген авылда яши. Менә узган ел беренче сыйныфка нибары бер бала укырга кергән. Димәк, киләчәктә авылда бөтенләй кеше калмаска мөмкин бит? – дип, күңелен борчыган мәсьәләне дә күтәрде ул.

Шулай да без тел очында торган соравыбызны да юлладык аңа: «Фермер булып эшләп, тормышны алып барып, гаиләне туйдырып буламы?»

– Була, – дип җавап бирде Салават. – Теләк кенә булсын, эшләсәң – бар да була. Механизаторларның, терлекчеләрнең үз авылыбыз кешеләре булуы бик яхшы, ышанычлы. Әти-әниләр, энекәшнең авылда торуы да уңайлы. Энем – агроном. Бик күп эшләрдә аның белән киңәшләшеп эшлим. Киләчәктә, мөмкинлек булса, тагын да җәелергә исәп бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖЫЛЫ УЧАК

2024 гаилә елы

Кукмара

Мортазиннар өчен гаилә ул – җылы бер учак, тормыш күңелсезлекләреннән ышыклану һәм сөенечләрне уртаклашу урыны. Хуҗабикә Гөлзия исә аны болайрак сурәтләп бирде. Гаилә ул – әни, кызым, матурым дигән наз тулы сүзләр дә, җәмгыятьнең тотрыклы нигезе дә. Әнә шуңа Мортазиннар ил башлыгын сайлауга да бергәләп җыена.

– Сайлау ул – җаваплылык. Киләчәк – безнең ничек тавыш бирүебезгә бәйле. Туган илем, гаиләм, балаларымның киләчәге нинди булыр? Ил язмышы хәл ителгән көннәрдә бу сорауга үз тавышың белән җавап бирергә кирәк. Без гаиләбез белән сайлауга барачакбыз. Ул балалар күңелендә бәйрәм булып истә калыр. Без исә үз тавышыбызны биреп, бурычыбызны үтәп кайтырбыз. Бу көннәрдә пассив һәм битараф булырга ярамый.

Бусы – гаилә башлыгы сүзләре. Ире Алмаз – үзмәшгуль. Гөлзия күппрофильле лицейда 18 ел укытучы булып эшли. Башта туган телне укыткан, хәзер инглиз телен өйрәтә. Алмаз белән өч бала тәрбиялиләр. Олысы Булат 8 нче сыйныфта укый. Самбо буенча Татарстанның җыелма командасы составында шөгыльләнә. 2 нче сыйныфта белем алган Самат исә спортның хоккей төрен сайлаган. Алар районда гына түгел, республика ярышларында да җиңү яулый. Төпчекләре Моратка – 2 яшь, ул бакчага йөри. Анысы туп тибәргә ярата икән. Футболчы булыр дип көтәләр. Булат – Гөлзиянең беренче никахыннан, әмма Алмаз аны үз улы кебек кабул иткән. Ун ел эчендә яшь гаилә бер-берсен аңларга өйрәнеп беткән инде. Балалары – яшәү мәгънәсе. Булат ярышка китсә, аны сагынып, табын корып көтеп торалар.

> **Владимир ПУТИН:**
> Гаиләнең төп бурычы – балаларны тудыру һәм тәрбияләү. Бу – бөтен күпмилләтле халыкның дәвамы дигән сүз.
> **(Федераль Җыенга Юлламадан)**

Гаиләнең үз традицияләре бар. Яңа нигезгә күчкәннән бирле ел саен, Корбан чалалар. Әниләре Наилә абыстай, мөмкинлегегез булган саен, чалыгыз, дип әйтә икән. Табигатькә чыгу гадәте дә онытылмаган. Туган көннәрендә учак ягып, шашлык пешерәләр. Мортазиннар бүләкләр бирешергә дә ярата. Көзен кәрнизгә гаиләдәге һәр кеше исемен язып, оекбашлар элеп куялар. Шунда һәркем бүләген сала. Сере исә Яңа ел төнендә генә чишелә.

Тату гаилә серләрен дә белештек. Гөлзия әйтүенчә, баштарак вак нәрсәләргә игътибар итсәләр, хәзер яшь барган саен, күп нәрсәләргә күз йомалар.

– Әти-әни безне, бер-беребезгә юл куеп, сабыр булып яшәргә өйрәтте. Кирәкмәгәнне ишетмәскә һәм күрмәскә тырышабыз. Сабырлык һәм ышаныч кирәк. Ышаныч булмаса, гаилә юк дигән сүз. Хатын-кыз ир-атны үзенә ияртеп барырга тиеш дип уйлыйм. Алмаз мин тәкъдим иткәнне хуплап, көч биреп торырга тырыша, – ди ул.

Бер-берсенә «матурым» дип дәшәләр. Очрашып йөргән вакыттан калган гадәт монысы. «Ачу чыкса, Алмаз, дим. «Нәрсә булды инде тагын?» – ди ул, аптырап. Тәмле телле булу кирәк. Балаларга да, улым, кызым, дип дәшсәң, матур бит. Без үскәндә алай түгел иде. Әти-әни тату торса да, «матурым» дип дәшкәннәрен ишеткәнем юк. Элеккеге кешеләр өчен кыргыйрак кебек тоеладыр, күрәсең. Син булдырасың, дип әйтергә яратам. Бу сүзне ирем дә, балаларым да, укучыларым да ярата. Нинди дер очыну барлыкка килә. Спортта да үсендереп торам», – ди күпбалалы ана.

Гөлзия өйдә генә түгел, мәктәптә дә таләпчән. Әмма укучылары белән һәрвакыт бер дулкында. Үзен дә әти-әнисе «бар нәрсә дә ярый» дип тәрбияләмәгән. Кием яки башкасын сорап аптыратмаган алар. Хәзер үзе дә балаларын, экономияләргә өйрәнегез, дип үстерә. Һәрберсенең «копилка»сы бар. Акчаны шунда җыеп барып, кирәк чакта тоталар.

Таләпчәнлек димәктән, әниләре балаларына, спорт белән уку бер-берсенә комачауларга тиеш түгел, дигән таләп куйган. Әгәр начар билге ала башласалар, спортка вакытны киметергә туры киләчәк. «Спортчылар – үрнәк, аларга карап башкалар тырышырга тиеш», – дип үстерә улларын Мортазиннар. Шуңа начар билге алырга тырышмыйлар.

Әти нәрсә эшли, балалар да шуның янында чуалып йөрергә тиеш. Тәртип шундыйрак. Ни өчен дигәндә, өчесе дә малайлар бит. Ә Алмазның кулы алтын, бар хезмәткә өйрәтерлеге бар. Сантехника, слесарь, ремонт, хәтта тегү эшен дә булдыра. Балалар барысын да күреп, өйрәнеп үсә. Мортазиннарда эш бүлү гадәте дә юк. Ашарга кем җитешә, шул пешерә. Гөлзия үзе дә ир-ат эше дип тормый. Утын ярганда, төягәндә дисеңме, башкасындамы – ире янында бөтерелә. Ул ишегалдында мәш килгәндә, өйдә тик ята алмый. Яз җиткәч, җир өлгергәч, бергәләп бакча җыештырырга чыгачаклар. Өйне дә бергә юалар. Алмаз түшәмне юарга булыша. Өмә ясаганда, һәр эш күңелле була бит.

Сәрия МИФТАХОВА

ИГЪТИБАР, ИШЕКЛӘР АЧЫЛА!

«АК БАРС»НЫҢ ҖИҢЕЛҮ БӘЯСЕН КЕМ ТҮЛӘР?

Спорт

Биш елдан соң шул ук хәл кабатланды. «Ак барс» үз тарихында икенче мәртәбә Гагарин Кубогы өчен көрәштән беренче раундта ук төшеп калды. 2019 елдагы уңышсызлыктан соң Зиннәтулла Билалетдинов үз вазыйфасыннан китеп барган иде. Бу юлы ни булыр?

Әйе, без көткәнчә килеп чыкмады. Бик күпләр ялгышты. «Ак барс»ның «Автомобилист»ны җиңәсен фаразладык. Команда даими чемпионат барышында тотрыксыз чыгыш ясаса да, уенчылар плей-оффта бер йодрыкка тупланыр дип уйладык. Билалетдиновның тәҗрибәсенә өметләндек. Әмма чын «Ак барс»ны биш очрашуның нибары берсендә күрдек. Казан командасы көндәшенә түгел, сезон дәвамында хәл ителмәгән үз проблемаларына җиңелде. «Мондый хәл икенче тапкыр килеп чыкты. Беренче мәртәбә без чемпион исемен яулагач булган иде. Былтыргы финалдан соң янә шул хәл кабатланды. 2019 елда «Авангард»ка каршы узган уеннарда ни өчен шулай булганын беләм. Миңа калса, бу юлы да шуның аркасында зыян күрдек», – диде баш тренер 8 март кичендә күңелсезлек белән тәмамланган очрашудан соң. Нәрсә турында сөйли баш тренер: уенчылар, тренерлар арасындагы мөнәсәбәт хакында түгелме? Бу сорауны да бирделәр. Билалетдинов исә андый проблема барлыгын да танымады, кире дә какмады. «Әйтәсен әйттем инде», – диде ул. Билалетдинов күпне күргән һәм кайда ни сөйлисен яхшы белә. Алайса, Казан командасының журналистлар янында иң ихлас һәм туры сүзле уенчысы Артем Лукоянов әйткәннәргә колак салыйк: «Көндәш безне остарак булганга түгел, ә бергәләшеп эшли алганга җиңде. Ике яки өч түгел, ә бергәләшеп эшләгәндә генә җиңеп була. Бу хурлыклы уен өчен барыбыз бергә җавап бирәчәкбез».

Сезон алдыннан «Ак барс» Гагарин Кубогы өчен көрәштә төп фаворит саналды. Исемнәргә генә күз салыгыз: Александр Радулов, Вадим Шипачев, Вячеслав Войнов болай да бар иде, узган җәй алар янына Дмитрий Яшкин белән Дамир Җәгъфәровны чакырдылар. Нәтиҗәсе? Дамир «Ак барс»та бөтенләй уйный алмады, аны «Авангард»ка җибәрделәр. Дмитрий яхшы гына башласа да, сезон уртасында имгәнеп, сафтан чыкты. Бозга ул плей-офф башлангач кына чыкты. Әмма сериянең язмышын хәл итәрлек өлеш кертә алмады.

Калганнар нәрсә? Радулов, һәрвакыттагыча, көндәшләренә дә, үз иптәшләренә дә тынычланырга ирек бирмәде. Акырынды-җикеренде, тик элеккеге очколар инде күренми. Артыгын тырышып аткан чаклары күп булды. «Автомобилист»ка каршы узган икенче очрашу – әнә шуның бер дәлиле. Көндәшен дә имгәтте, командасын да. Гадәти уеннарда бер рекорд артыннан икенчесен яңартучы Шипачев, плей-офф җиткәч, 5 очрашуда 1 алка кертте һәм 1 пас бирде. Ике мәртәбә Стэнли Кубогын откан Войнов КХЛда иң зур хезмәт хакы алган сакчылардан санала. «Ак барс»тагы уены исә болай дип уйларга мәҗбүр итә: «Динамо» тикмәгә генә җибәрмәгән икән.

Казанда әнә шул уенчылардан берберсе өчен барысына да әзер булырлык команда төзи алмадылар. Төп гаеп кемдә, Зиннәтулла Билалетдинов аркасында шулай килеп чыктымы? Алай дисәң, узган ел ул командасын финалга кадәр алып барып җиткерде, ә быел исә мартта ук ялга чыгарды. Тәҗрибәле остаз баш тренер вазыйфасында калырга бик озак уйлаганнан соң гына ризалык биргән иде. Әллә көче җитмәдеме? «Көчем финалга кадәр җитәргә тиеш иде», – диде ул соңгы очрашудан соң.

ak-bars.ru

2019 елгы җиңелү командада зур үзгәрешләр китереп чыгарды. Зиннәтулла Билалетдинов урынына Дмитрий Квартальнов килде. Состав та сизелерлек яңарды. Быел баш тренер белән ни буласын фаразлап булмый. Билалетдиновка Татарстанда хөрмәт зур, димәк, аның үз фикеренә дә колак салачаклар. Ә менә уенчыларга килгәндә, берьюлы 14 хоккейчының килешү вакыты тәмамлана. Араларында Радулов, Галиев, Адамчук кебек өметне акламаучылар да, Семенов, Билалов, Лукоянов кебек команда уенында мөһим урын алып торган хоккейчылар да бар.

«Ак барс» җитәкчелеге инде хәзердән үк киләсе сезон турында уйланса, КХЛда Гагарин Кубогы өчен көрәш әле кыза гына. Көнчыгыш конференциясендә чирекфиналга чыккан барлык командалар билгеле: «Металлург», «Авангард», «Автомобилист» һәм «Трактор». Көнбатышта исә СКА, «Локомотив» һәм «Спартак» үз көндәшләрен җиңде. Чирекфиналда кемнең кемгә каршы уйныйсы ике «Динамо» арасындагы серия тәмамлангач ачыкланачак. Мәскәү командасы җиңсә, алар – «Трактор»га, СКА – «Автомобилист»ка, «Металлург» – «Спартак»ка, «Авангард» исә «Локомотив»ка каршы уйнаячак.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 228

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+